КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 14 май г.Казань № 390

2019 елда спутник телевидениесе сигналын кабул итү өчен җиһаз сатып алу һәм аны урнаштыру (монтажлау, көйләү) чыгымнарын компенсацияләү турында

Татарстан Республикасында тулы масштаблы цифрлы эфир телевидениесенә күчкәндә цифрлы эфир тапшырулары булган зонадан читтә урнашкан торак пунктларда яшәүче социаль якланмаган гражданнарны спутник телевидениесенә тоташтыруда адреслы ярдәм күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елда җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында халыкның җан башына билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән артмаган йорт хуҗалыкларына спутник телевидениесе сигналын кабул итү өчен җиһаз сатып алу һәм аны урнаштыру (монтажлау, көйләү) чыгымнарының бер тапкыр бирелә торган компенсациясен спутник телевидениесе сигналын кабул итү өчен җиһазның һәм аны урнаштыруның (монтажлау, көйләү) факттагы кыйммәте, әмма 7 300 сумнан артыграк булмаган күләмдә билгеләргә.

2. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2019 елда спутник телевидениесе сигналын кабул итү өчен җиһаз сатып алу һәм аны урнаштыру (монтажлау, көйләү) чыгымнарының бер тапкыр бирелә торган компенсациясен түләү тәртибе турындагы нигезләмәне;

2019 елда спутник телевидениесе сигналын кабул итү өчен җиһаз сатып алу һәм аны урнаштыру (монтажлау, көйләү) чыгымнарының бер тапкыр бирелә торган компенсациясен түләү чыгымнарын финанслау тәртибе.

3. Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына спутник телевидениесе сигналын кабул итү өчен җиһаз сатып алу һәм аны урнаштыру (монтажлау, көйләү) чыгымнарының бер тапкыр бирелә торган компенсациясен исәпләп чыгару өчен кирәкле программа тәэминатын әзерләүне тәэмин итәргә.

4. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

спутник телевидениесе сигналын кабул итү өчен җиһаз сатып алу һәм аны урнаштыру (монтажлау, көйләү) чыгымнарының бер тапкыр бирелә торган компенсациясе түләү чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү «2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2018 елның 21 ноябрендәге 88-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында әлеге максатлар өчен каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла;

спутник телевидениесе сигналын кабул итү өчен җиһаз сатып алу һәм аны урнаштыру (монтажлау, көйләү) чыгымнарының бер тапкыр бирелә торган компенсациясен түләү турындагы мәгълүмат «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына һәм Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры                                                                 А.В.Песошин